СОВЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

27.07.2023 | с. Набережные Моркваши | 36-215

Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Моркваши авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакындагы нигезләмәнең үз көчен югалтуын тану турында.

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, “Коррупциягә каршы тору турында” 25.12.2008 ел N 273-ФЗ номерлы Федераль законнар, “Муниципаль вазыйфа яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе турында” 19.07.2017 ел N 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакындагы 13.03.2023 №31-190 Нигезләмә үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге И.Х.Гаязов